**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 24

15.12. 2020 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында яңа редакциядәге нигезләмә хакында» 2018 ел, 24 август, 158 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 ел, 13 ноябрь, 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында яңа редакциядәге нигезләмә хакында» 2018 ел, 24 август, 158 номерлы карары белән расланды) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

28 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 28.19.1. пункты өстәргә

«28.19.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәте вазыйфасын биләгән затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта башкарыла.

Күрсәтелгән бурыч тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә хәл ителгән очракта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү мондый билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.»

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы сайтында интернет челтәрендә: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. Карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы
Совет Рәисе

К.К.Гилманов